КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 июнь г.Казань № 517

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган

Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «26. | Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Татарстан Республикасының уңай туристлык имиджын булдыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләре күләмен һәм төрлелеген арттыру, Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү, конкурентлыкка сәләтле туристлык продуктын формалаштыру һәм аны перспективалы туристлык базарларында таныту, республика туристлык продуктының сыйфатын, туристлык индустриясе объектларында Россия Федерациясе стандартларын һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, туристларга хезмәт күрсәтүдә кунакчыллык дәрәҗәсен күтәрү»; |

37 – 38 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «37 | Татарстан Республикасында | Татарстан Респуб- | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Та- | Массакүләм физик культураны тотрыклы үстерү; Татарстан |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | физик культура һәм спорт-ны үстерү | ликасы Спорт ми-нистр-лыгы | тарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау ми-нистрлыгы, Татарстан Республикасы Сәла-мәтлек саклау ми-нистрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татар-стан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министр-лыгы, «Татарстан Рес-публикасы Министр-лар Кабинеты кар-шындагы Татарстан Республикасы Икъти-садый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учре-ждениесе, Татарстан Республикасы Төзе-леш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министр-лыгы, «Татарстан Рес-публикасы Баш инве-стиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе, «Та-тарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы, Татарстан Республи-касы җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | Республикасында югары спортны үстерү; Татарстан Республикасының спорт резервын формалаштыру; халыкның сәламәтлеген ныгыту; республиканың спорт имиджын ныгыту; республиканың спорт инфраструктурасын үстерү; спорт корылмаларын модернизацияләү; 2018 елгы FIFA футболы буенча дөнья чемпионатыннан соң өйрәнү мәйданчыкларын нәтиҗәле файдалану |
| 38 | Татарстан Республи-касында яшьләр сәясәтен үстерү | Татар-стан Респуб-ликасы Яшьләр эшләре ми- | Татарстан Республи-касы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Та-тарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау ми- | Татарстан Республикасының яшьләр сәясәтен үстерү; ба-лалар һәм яшьләр өчен ча-ралар үткәрү; балалар һәм яшьләр ялын, аларны савык-тыруны, эш белән тәэмин итүне оештыру системасын |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | нистр-лыгы | нистрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | саклау; төрле типтагы һәм милек рәвешләрендәге лагерьларны, савыктыру учреждениеләрен үстерү; республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм модернизацияләү; Татарстан Республикасы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру; балаларның тормыш эшчәнлеген комплекслы үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм тормышта авыр хәлдә калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү; яшьләр белән оештыру-тәрбия эшен гамәлгә ашыру; ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин